СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.11.2021 с. Набережные Моркваши 13-91

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 7 декабренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Яр буе Морквашы авылының Солнечная урамында балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Яр буе Морквашы авылы, Солнечная урамы, 5 нче йорт янында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов